**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 16 маендагы 1523 номерлы карары**

**2025 елга «Шәһәр трансформациясе үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны раслау турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 ноябрендәге 10406 номерлы «Казан шәһәре муниципаль учреждениеләренә карата муниципаль бирем формалаштыру һәм муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында»гы, 2025 елның 12 мартындагы 660 номерлы «Шәһәр трансформациясе үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарлары нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елга «Шәһәр трансформациясе үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән норматив чыгымнар муниципаль бирем буенча тиешле эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру өчен кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, шулай ук аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Документ создан в электронной форме. № 71079-Инф от 19.06.2025. Исполнитель: Переводчики
Страница 2 из 3. Страница создана: 19.06.2025 13:47
ЕМСЭД

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2025 елның
16 маендагы 1523 номерлы
карарына кушымта

**2025 елга «Шәһәр трансформациясе үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнар**

| № т/б | Муниципаль эш (хезмәт) исеме | Муниципаль эш (хезмәт күрсәтү) эчтәлеге | Эшне (хезмәтне) башкаруга чыгымнар, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Мәгълүмат-телекоммуникация инфраструктурасының мәгълүмат системаларын һәм компонентларын булдыру һәм үстерү | Мәгълүматларны эшкәртү үзәге | 28276 |
| 2 | Оешма эшчәнлеген административ тәэмин итү | Проектлар белән идарә итү | 11768 |
| **БАРЛЫГЫ** | | | 40044 |

___